| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.04.2021 Казан ш. № 1121-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.12.2013 № 4083-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән документациягә туры китереп, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Казаньгоргаз») милке булган, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 30.12.2013 № 4083-р карары (алга таба - № 4083-р Карар) белән урнаштырылган 2246,6. м. озынлыктагы, 5936 инвентарь номерлы газүткәргечнең, түбән басымлы җир асты газүткәргече участогы үзгәртелү сәбәпле, әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклау зоналарын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә

булган әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге 2193,2 м озынлыктагы, 37277 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешләренең саклау зоналарын, түбән басымлы җир асты газүткәргече участогы үзгәртелү сәбәпле, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты һәм җир өсте объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә расларга.

3. Әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән һәм өлешчә яки тулысынча күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән җир кишәрлекләренә 37277 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешләренең эксплуатация срогында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләгән Территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 4083-р карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә урнаштырылган 517,9466 км озынлыктагы, әлеге карарның 9 нчы кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү газүткәргеченең «Кадастровый центр «Граница» ҖЧҖ, «Кадастр недвижимости” ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә.»;

3 нче кушымтада 37277 инвентарь номерлы газүткәргеченә туры килә торган юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 37277 | - | Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге | 2193,2 | d = 63 түбән басым | 16 – 16.0 – 10.2002 – 1640.1 от 10.07.2002 |

1 нче кушымтадагы кадастр номерлы җир кишәрлегенә туры килгән юлларны 11 нче кушымтадан төшереп калдырырга;

1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтадагы юллар белән тулыландырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
07.04.2021 № 1121-р карарына 1 нче кушымта

# Бүлгеч газүткәргечләренең саклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре турында белешмә

| Бүлүче газүткәргечнең инвентарь номеры (ОС) | Адрес | Хокук төре | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлеге урнашкан җир куллану бердәм кадастр номеры | Саклау зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җирләр категориясе | Мәйданы | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлегенең милек иясе | Рөхсәт ителгән куллану төре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37277 | ТР, Биектау мб, Биектау авыл җирлеге, Пермяки ав., Азин ур., 6 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен | | 16:16:190302:374 | Торак пунктлар җирләре | 182,00 | Нурмехамметов Ринат Рустамович | Ишегалды участоклары белән шәхси торак йортлар |
| 37277 | ТР, Биектау мб, Биектау авыл җирлеге | Авыл хуҗалыгы өчен | | 16:16:000000:6173 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр | 0,00 | "Бирюли" ЯАҖ | Авыл хуҗалыгы өчен |

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
07.04.2021 № 1121-р карарына 2 нче кушымта

## Бүлгеч газүткәргечләренең саклау зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре турында белешмә

| Бүлүче газүткәргечнең инвентарь номеры (ОС) | Адрес | Хокук төре | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлеге урнашкан җир куллану бердәм кадастр номеры | Саклау зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры | Җирләр категориясе | Мәйданы | Саклау зонасында урнашкан җир кишәрлегенең милек иясе | Рөхсәт ителгән куллану төре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 37277 | ТР, Биектау мб, Биектау авыл җирлеге, Пермяки ав., Азин ур., 6 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен | | 16:16:190302:374 | Торак пунктлар җирләре | 1,51 | Нурмехамметов Ринат Рустамович | Ишегалды участоклары белән шәхси торак йортлар |
| 37277 | ТР, Биектау мб, Биектау авыл җирлеге | Авыл хуҗалыгы өчен | | 16:16:000000:6173 | Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр | 0,54 | ЗАО "Бирюли" | Авыл хуҗалыгы өчен |